ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 гыйнвар 2026ел. № 02

Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәплəү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 20 августындагы 5453 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

УПРАВЛЕНИЕ
ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН
АЛЫП БАРУ
ИДАРӘСЕ

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 12 гыйнварындагы
2 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Транспорт чарасын куюю хезмәтләре | | | |
| 1 | Җиңел автомобиль | ай/тәүлек | 1 200,00/100,00 |
| 2 | Микроавтобус | ай/тәүлек | 1 400,00/150,00 |
| 3 | Трактор | ай/тәүлек | 1 400,00/150,00 |
| 4 | Йөк автомобиле | ай/тәүлек | 1 600,00/150,00 |
| II. Шугалакның прокат хезмәтләре | | | |
| 1 | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 100,00 |
| 2 | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 150,00 |
| 3 | Тимераякларны үткенләү | 1 хезмәт | 200,00 |
| 4 | Шугалакка керү | кеше/1 сәгать | 50,00 |
| III. Командалы спорт төрләре (футбол) буенча чаралар оештыру һәм үткәрү | | | |
| 1 | Футбол кыры | 1 сәгать | 4 000,00 |
| 2 | Футбол кыры 1/2 | 1 сәгать | 2000,00 |

* Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына (тол калган хатыннарына), катнашучыларга транспорт чарасын кую хезмәтләренә 30 % күләмендә ташлама бирелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева